КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 март г.Казань № 191

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елның III – IV кварталларында һәм 2018 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән, шулай ук Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә урнаштырылган һәм 2016 елда грант алуга конкурста катнашу өчен гаризалар биргән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елның III – IV кварталларында һәм 2018 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән, шулай ук Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә урнаштырылган һәм 2016 елда грант алуга конкурста катнашу өчен гаризалар биргән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында»

2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 август, 557 нче; 2018 ел, 15 сентябрь, 784 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын (алга таба – медицина оешмалары, табиблар-белгечләр, грант) гамәлгә кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә.»;

3 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибен;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган 2017 елның III – IV кварталларында һәм 2018 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән, шулай ук Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә урнаштырылган һәм 2016 елда грант алуга конкурста катнашу өчен гаризалар биргән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибендә:

исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы

табиб-белгечләренә, табибларына 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртиптә 2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына торак шартларын яхшырту өчен 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары (алга таба – медицина оешмалары, табиблар-белгечләр, грант) бирү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.»;

3 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең башка субъектларыннан яки Татарстан Республикасының муниципаль районнарыннан медицина оешмаларына эшкә яңадан килгән (күчеп килгән) йә Казан шәһәреннән, Чаллы шәһәреннән авыл җирлегендәге медицина оешмасына эшкә яңадан килгән (күчеп килгән), 55 яше тулмаган табиб-белгеч тарафыннан медицина оешмасы белән бер ставкага төп эш урыны шартларында хезмәт шартнамәсе төзү;»;

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» һәм «д» пунктчалары өстәргә:

«г) табиб-белгечнең тиешле белемен һәм квалификациясен, өстәмә һөнәри белемен, гыйльми дәрәҗәсен, квалификация категориясен раслый торган документларның тиешле рәвештә таныкланган күчермәләрен (булган очракта);

д) табиб-белгечнең һәм аның гаилә әгъзаларының (иренең (хатынының), балаларының) медицина оешмасы урнашкан торак пунктта торак урыны булуы турындагы мәгълүматның Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булмавы турындагы хәбәрнамәне»;

6 нчы һәм 7 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2017 елның III – IV кварталларында һәм 2018 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән, шулай ук Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә урнаштырылган һәм 2016 елда грант алуга конкурста катнашу өчен гаризалар биргән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртиптә 2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына торак шартларын яхшырту өчен 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары (алга таба – медицина оешмалары, табиблар-белгечләр) бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе билгеләнә.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин